| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.12.2018 Казан ш. № 10-114/кс

Эчәргә яраклы суга 2019 елга тарифлар билгеләү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга тарифларны әлеге карарга кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарга кушымтада каралган салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 5 декабрендәге 10-114/кс
номерлы карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга тарифлар, 2019 елга календарь бүленеш белән

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | |
| 1 | "Түбән Ослан" муниципаль унитар предприятиесе* | 27,94 | 28,86 |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | |
| 2 | "УК Загородный Клуб" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* (Дубровка поселогы кулланучылары өчен) | 37,18 | 37,18 |
| 3 | "Октябрь инженерлык челтәрләре" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | |
| 3.1 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)** | 32,27 | 33,12 |
| 3.2 | Башка кулланучылар (тарифларны күрсәткәндә НДС исәпкә алынмаган) | 26,89 | 27,60 |
| 4 | "Осиново" идарәче компаниясе" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 14,59 | 15,01 |
| 4.1 | Яңа Тура авылы кулланучылары | 15,22 | 15,61 |
| 4.2 | Ремплер, Воронино авыллары кулланучылары | 14,87 | 15,29 |
| | Кама Тамагы муниципаль районы | | |
| 5 | "УЮТ" муниципаль унитар предприятиесе* | 21,61 | 22,14 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге